ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

«03» апрель 2024 ел Калмия авылы №8

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Кырныш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Кырныш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Кырныш авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 октябрендәге 9/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Кырныш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Кырныш авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә 10.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче Кырныш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

(Центральная урамында һәм киселешләрдә юл төзелеше буенча эшләр башкару, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 14 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Кырныш авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Центральная урамында һәм киселешләрдә юл төзелеше буенча эшләр башкару, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Калмия авыл җирлеге, Калмия авылы, Молодежная ур., 23 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Калмия авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.М.Харрасова